**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлегенең Урта Ушма поселогында**
**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

20 ноябрь, 2020 ел №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23нче маддәсе нигезендә Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлегенең урта Ушма торак пунктында гражданнар җыены үткәрелде.:

1. 2021 елда үзсалым Балтач районы Кече Лызи авыл җирлегенең урта Ушма авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган яшәүчедән, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы һәм тыл ветераннарыннан, ялгыз карт гражданнардан, балигъ булмаган балалар тәрбияләүче тулы булмаган гаилә әгъзаларыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 400 сум күләмендә кертелә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- урта Ушма авылында плотина буенда юлга вак таш салу.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән Балтач муниципаль районының рәсми сайтында халыкка игълан итәргә baltasi.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында pravo.tatarstan.ru.

4. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлеге башлыгына әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Кече Лызи авыл җирлеге башлыгы С. А. Мухин